ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ  АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАБАР-ЧЕРКЕНЕ  АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2024 ел, 19 февраль №121

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Табар-Черкене  авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Табар-Черкене  авыл җирлеге советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар-Черкене авыл җирлеге Советының 2019 елның 8 ноябрендәге 127 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Табар-Черкене авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12.2 пунктча өстәргә:

«12.2) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы  федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) булган  капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи;».

2.Әлеге карарны а Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм җирлекнең мәгълүмат стендлары аша халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Табар-Черкене авыл җирлеге Башлыгы,
Табар-Черкене авыл җирлеге Советы рәисе Р.Х.Ибатуллин